| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**17.08.2018** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1676** |

Зеленодольск муниципаль районында 2018-2019 уку елында Россия Федерациясе Кораллы Көчләре өчен хәрби-учет белгечлекләре буенча гражданнарны әзерләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1999 елның 31 декабрендәге «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләү турындагы нигезләмәне раслау турында» 1441 номерлы карарын үтәү йөзеннән һәм гражданнарны хәрби-учет белгечлекләре буенча хәрби хезмәткә әзерләүне камилләштерү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**:

1. Зеленодольск муниципаль районында 2018-2019 уку елында гражданнарны хәрби-учет белгечлекләре буенча әзерләүнең төп чаралары планын расларга(кушымта).
2. Бирем нигезендә хәрби-учет белгечлекләре буенча гражданнар тарафыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы Хәрби комиссариатына Татарстан Республикасы ДОСААФ төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенең Зеленодольск җирле оешмасын сайлап алуны һәм комплектлаштыруны тәэмин итәргә.
3. "Армиягә, авиация һәм флотка ирекле ярдәм күрсәтү җәмгыяте төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенең Зеленодольск җирле оешмасы (Зеленодольск МО РОГО ДОСААФ РТ) советы рәисе Г.В. Мошковка:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәреЗеленодольск районы Хәрби комиссариаты белән берлектә хәрби-учет белгечлекләре буенча белем алу өчен Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә чакырылырга тиешле гражданнарны җыюны үткәрергә;
- укыту чоры башланганчы уку-укыту материаль базаны әзерләргә, шул исәптән җылыту сезоны башланганчы һәм кышкы чорда лаборатория-гамәли дәресләр үткәрү өчен класс-кабинетлар әзерләргә.

4. Югары һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә 2019 елда сәламәтлек торышы буенча яраклы һәм 2019 елда хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле чыгарылыш укучыларын сайлап алырга һәм ТР

ДОСААФына хәрби-хисап белгечлекләре буенча укырга җибәрергә. Башкарылган эшләр турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы Хәрби комиссариатына тапшырырга.

5. «Зеленодольск шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры С.В. Гататдиновага (килешү буенча) хәрби хезмәткә чакырылучылар арасыннан билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган вакытлыча эшләмәүче гражданнарны ачыкларга һәм аларны ТР ДОСААФка укырга җибәрергә. Башкарылган эшләр турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы Хәрби комиссариатына тапшырырга.

6. «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы Т.В. Сабурскаяга (килешү буенча) хәрби-хисап белгечлекләре буенча укыту өчен гражданнарны җибәргәндә профилактик медицина тикшерүләрен оештырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен конторльдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.В. Старостинга йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сапожников

ЗМР БК карарына кушымта
____________2018 № ________

Зеленодольск муниципаль районында 2018-2019 уку елына хәрби-учет белгечлекләре буенча гражданнарны әзерләү буенча төп чараларның
**ПЛАНЫ**

| № т/б | Чараның атамасы | Җаваплы башкаручы | Башкару срогы |
|---|---|---|---|
| **I. Гражданнарны хәрби-учет белгечлекләре буенча әзерләү** | | | |
| 1. | ТР ДОСААФта хәрби-учет белгечлекләре буенча әзерләүгә җибәрү өчен хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарны алдан сайлап алу | Мәгариф учреждениеләре, «Зеленодольск шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ, Зеленодольск муниципаль районының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы Хәрби комиссариаты җитәкчеләре | Уку елы дәвамында |
| 2. | ТР ДОСААФта хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарны хәрби-учет белгечлекләре буенча әзерләүне оештыру | Зеленодольск МО РОГО ДОСААФ РТ | 01.10.18-20.02.2019, 01.03.19-20.07. 2019 |
| 3. | Зеленодольск МО РОГО ДОСААФ РТ уку процессын һәм анда йөрүне контрольдә тоту | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре, Зеленодольск муниципаль районының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, Зеленодольск МО РОГО ДОСААФ РТ | Уку елы дәвамында |
| **II. Медицина таныклавы һәм медицина тикшерүе** | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Хәрби-учет белгечлекләре буенча әзерлек барышында гражданнарны медицина тикшерүен оештыру һәм уздыру | «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ<br>Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы хәрби комиссариаты | Сентябрь, 2018г февраль, 2019г. |
| **III. Контроль һәм ярдәм күрсәтү** | | | |
| 1. | ТР Зеленодольск МБ РОГО ДОСААФ базасында гражданнарны хәрби исәпкә кую белгечлекләре буенча комплектлау һәм әзерләү барышын контрольдә тоту | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре, «Зеленодольск шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ җитәкчеләре | Ел дәвамында |
| 2. | Зеленодольск МО РОГО ДОСААФ РТ чыгарылыш имтиханнарын үткәрүне контрольдә тоту | ТР Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы комиссариаты, Зеленодольск МО РОГО ДОСААФ РТ | Чыгарылыш имтиханнарының графигы буенча |